ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ　　　　　　　　　　　　КАРАР

______________　　с. Верхний Услон　　______________

«Югары Ослан муниципаль районы мәгариф учреждениеләрендә укучыларны тукландыруны оештыру турында «21.10.2022 ел, №1248 Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитетының карарына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 22 ноябрендәге 1355 номерлы карарына өстәмәләр кертү турында

Балаларны социаль яклау, аларның сәламәтлеген саклау, Югары Ослан муниципаль районының гомуми белем бирү оешмаларында укучыларның баланслы кайнар туклану нормаларын үтәүне тәэмин итү максатларында, "Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында" 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 29.12.2012 ел, № 273 Федераль закон нигезендә "Татарстан Республикасында халыкның аерым категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында" 2004 елның 17 декабрендәге 542 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары (79 статьяның 7 пункты), «Дәүләт мәгариф оешмаларында башлангыч гомуми белем бирү программалары буенча укучыларны бушлай кайнар туклану белән тәэмин итүгә норматив чыгымнарны һәм башлангыч гомуми белем бирү программалары буенча укучыларны кайнар тукллануның уртача бәясен раслау турында» 2022 елның 14 сентябрендәге 991 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “2023 елга айлык акчалата һәм башка төр түләүләр турында" 2022 елның 1 сентябрендәге 934 номерлы карары, «Махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнар гаиләләренә һәм махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (үлгән) гражданнар гаиләләренә ярдәм итүнең өстәмә чаралары турында» 2022 елның 20 октябрендәге 1122 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән (2023 елның 20 мартына үзгәрешләр белән) Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитетының "Югары Ослан муниципаль районы мәгариф учреждениеләрендә укучыларны тукландыруны оештыру турында” 21.10.2022 ел, №1248 Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитетының карарына үзгәрешләр кертү хакында" 02.11.2022 ел, №1355 карарына өстәмә кертергә һәм 1.3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

- Махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнарның балалары һәм 4 һәм аннан күбрәк балалары булган гаиләләрдәге укучылар, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар, Россия Федерациясе Милли гвардиясендә хезмәт итүче хәрбиләр һәм затлар, Татарстан Республикасында формалаштырылган «Алга», «Тимер» батальоннарында хәрби хезмәт үтәүче гражданнар, махсус хәрби операция барышында хәрби бурычларны үз теләге белән үтәүче гражданнар, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр Министрлыгы хезмәткәрләре, Россия Федерациясе Федераль куркынычсызлык хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча махсус хәрби операция уздыру зонасына командировкага җибәрелгән, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (үлгән) гражданнарның югарыда күрсәтелгән категориядәге балаларына 64 сум 19 тиенлек кайнар төшке аш оештырырга, шул исәптән: субвенция хисабына 8 сум 80 тиен, җирле бюджет акчалары хисабына 55 сум 39 тиен.

2. Әлеге карар 2023 елның 20 мартында барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүне «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы мәгариф бүлеге» МКУ начальнигына йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе Р.А. Файрушин

Ф.М. Ахметова
8(84379)2-16-70